Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советы

Богородский авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

15 июнь, 2026 ел № 14

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 80 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә (2017 елның 21 августындагы 94 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 108 номерлы, 2019 елның 2 октябрендәге 156 номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 62 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 70 номерлы карарларга үзгәрешләр белән) нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Богородский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1) «Автомобильләр ремонтлау» Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Богородский авыл җирлеге, Богородский авылы, Комаров урамы, 33Б ж/к адресы буенча 1055 кв. м. мәйданлы, кадастр номеры 16:33:020108:815 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты.

2. Гавами тыңлаулар уздыруны оештыручыны - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) билгеләргә.

3. Гавами тыңлауларны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 03 июленнән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы Д.Ю. Булыгин